РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Урсаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 60,
Азнакаевский район, с.Урсаево,
423318,
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 60 нчы йорт, Азнакай
районы, Урсай авылы, 423318
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«27» октябрь 2025 ел.** **№**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Мөслим торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Җирле хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Урсай муниципаль җирлеге Уставы нигезендә, Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Мөслим торак пунктында Мөслим авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2025 елның 10 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Мөслим торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 11 ноябрендә 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенын үткәрү урыны-Мөслим авылы, Гафури ур., 31 зал Мөслим авылы мәдәният йорты;

3.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 27 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Мөслим авылы, Гафури ур., 31 йорт;

- Мөслим торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Мөслим торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез "Урсай авыл җирлегенең Мөслим авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан, 2 төркем инвалидларга 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы? :

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (авария хәлләрен бетерү, материаллар, җайланмалар сатып алу);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту);

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http//aznakayevo. tatar. ru адресы буенча, шулай ук махсус мәгълүмат стендларында:

- Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай ав., Үзәк ур., 60 й., Совет ур., 14
- Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури урамы, 31

урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә

Башлык: З.Х. Рәхимьянова